ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2025 Олы Кайбыч ав. 392

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты «2025 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен тарифларны раслау турында» 2024 елның 27 декабрендәге 489 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты «2025 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен тарифларны раслау турында» 2024 елның 27 декабрендәге 489 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм 1нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районынын рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 е. «29» 08
392 номерлы карарына
кушымта

2025 елга социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен

ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| т/б № | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2025е. 01 гыйнварыннан 2025е. 30 июненә кадәр | 2025е. 01 июленнән 2025е. 31 декабренә кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,92 | 1,08 |
| 2. | Торак бинага агымдагы агымдагы ремонт | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 3,88 | 4,56 |
| 3. | Йорт эчендәге инженерлык сүүткәргечләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 1,62 | 1,90 |
| 4. | Йорт эчендәге инженерлык канализация челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,88 | 1,04 |
| 5. | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 1,35 | 1,59 |
| 6. | Подъезд эче газүткәргечләренең тышкы фасадына техосмотр | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,61 | 0,71 |
| 7. | Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 1,31 | 1,54 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8. | Вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,95 | 1,11 |
| 9. | Тѳтенлекләргә техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 1,66 | 1,95 |
| 10. | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 3.24 | 3,81 |
| 11. | Йорт яны территориясен тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 4,47 | 5,25 |
| 12. | Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 7,20 | 8,46 |
| 13. | Дератизация | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,90 | 1,06 |
| 14. | Контейнер мәйданчыкларын карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,74 | 0,87 |